СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.10.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 72-291

с. Нижний Услон

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. Недоимканы, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варисларның мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас булмаган очракта, үлгәннәрнең яки вафат булган физик затларның пенялары һәм штрафлары буенча бурычлары, мирас ачылганнан соң бер ел дәвамында мирас алмаган очракта;

2) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында мәгълүмат булмаган һәм салым исәбенә куелган оешмаларның недоимкалар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары булу;

3) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгаруга бәйле рәвештә, әлеге недоимканы, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерү процедураларында булмаган физик затларның недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары булу мөмкин булмаган очракта, пеня һәм штрафлар буенча недоимкалар һәм (яки) бурычлар барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт узса;

4) бу недоимканы түләттерү срогы чыкканнан соң оешмаларның недоимкага исәпләнгән пенялары буенча бурычлары булу, алар исәпләнгән недоимка булмаганда.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге
Башлыгы Шайдуллин А.З.